**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“14” ноябрь 2025 ел. № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Яңа Шашы торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, тавыш бирү хокукына ия булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.
(Яңа Шаши авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); бензин триммеры сатып алу; үләннәр өчен чапкыч-ваклагыч сатып алу.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Яңа Шашы авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Яңа Шашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Яңа Шашы авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.